**ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

# КАРАР

«14» ноябрь 2025 ел №9

Зеленодольск муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге Советы нигезендә **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен Кабул итәргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Октябрь авыл җирлегендә рөхсәтсез калдыклар ташлау урыннарын бетерү.

2. Октябрь авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Октябрьский бистәсе, Беренче Май урамы, 5 йорт, Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Октябрьский бистәсе, Беренче Май урамы, 2 нче йорт (Октябрь авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы).

**Октябрь авыл җирлеге башлыгы урынбасары,**
**Совет рәисе** **М.В.Евдокимова**

Октябрьского сельского поселения
Октябрьский авыл җирлеге советы